КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 10 май г.Казань № 582

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Транспорт чараларын мотор ягулыгы сыйфатында табигый газ (метан) файдалануга яңадан җиһазландыру эшләрен башкаручы юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә яңадан җиһазландыруны башкаручы затлар тарафыннан күрсәтелгән эшләргә транспорт чаралары хуҗаларына ташламалар бирү белән бәйле алынмаган керемнәрен кире кайтару максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 21 июнь, 484 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 1 ноябрь, 1035 нче, 2022 ел, 10 сентябрь, 977 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Транспорт чараларын мотор ягулыгы сыйфатында табигый газ (метан) файдалануга яңадан җиһазландыру эшләрен башкаручы юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә яңадан җиһазландыруны башкаручы затлар тарафыннан күрсәтелгән эшләргә транспорт чаралары хуҗаларына ташламалар бирү белән бәйле алынмаган керемнәрен кире кайтару максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Сайлап алу, сайлап алуда катнашучының сайлап алу критерийларына, таләпләренә туры килүеннән һәм тәкъдимнәр (заявкалар) керү чиратыннан чыгып, тәкъдимнәр (заявкалар) нигезендә тәкъдимнәрне (заявкаларны) соратып алу юлы белән гамәлгә ашырыла.

Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы)

кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталындагы «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

Сайлап алуны үткәрү турында белдерү, тәкъдимнәр (заявкала) бирелә башлаган датага кадәрге бер эш көненнән дә соңга калмыйча, Россия Федерациясе бюджет системасының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге бердәм порталында һәм вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында https://mpt.tatarstan.ru/ урнаштырыла.

Сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә түбәндәгеләр хакында мәгълүмат бирелә:

сайлап алуны үткәрү сроклары;

тәкъдимнәр (заявкалар) бирә башлау яки кабул итүне тәмамлау даталарын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 календарь көннән иртәрәк була алмый);

вәкаләтле органның исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

бу Тәртипнең 19 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәләре;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган сайтның домен исеме, һәм (яки) челтәр адресы, һәм (яки) битләр күрсәткечләре;

бу Нигезләмәнең 5 һәм 8 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләр һәм сайлап алуда катнашучылар тарафыннан аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеге;

бу Тәртипнең 6 пункты нигезендә сайлап алу критерийлары, бу Тәртипнең 10 пункты нигезендә тәкъдимнәр (заявкалар) бирү тәртибе һәм тәкъдимнәр (заявкалар) формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләр;

тәкъдимнәрне (заявкаларны) кире алу тәртибе, тәкъдимнәрне (заявкаларны) кире кайтару (шул исәптән тәкъдимнәрне (заявкаларны) кире кайтару өчен нигезләр билгеләнә торган) тәртибе, тәкъдимнәргә (заявкаларга) үзгәрешләр кертү тәртибе;

бу Тәртипнең 13 пунктлары нигезендә сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (заявкаларын) карап тикшерү һәм бәяләү кагыйдәләре;

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибе, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасы;

сайлап алуда җиңүче тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә имза кую вакыты;

сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) субсидия бирү турында килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартлары;

сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңга калмыйча, Россия Федерациясе бюджет системасының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге бердәм порталында һәм вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алу нәтиҗәләрен урнаштыру датасы.»;

5 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуда катнашучылар чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмау. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

8 пунктның сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Федераль кагыйдәләргә 3 нче кушымтаның 1 пунктындагы алтынчы абзацы нигезендә газ баллоны үзебездә җитештерелгән булырга тиеш;»;

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Яңадан җиһазлау һәм техник хезмәт күрсәтү пунктларының Федераль кагыйдәләр таләпләренә туры килү-килмәвен тикшерү ел саен уздырыла. Яңадан җиһазлау һәм техник хезмәт күрсәтү пунктларын тикшерү тәртибе вәкаләтле орган боерыгы белән билгеләнә. Яңадан җиһазлар алыштыру һәм техник хезмәт күрсәтү пунктларын тикшерү буенча ведомствоара комиссиянең яңадан җиһазлау һәм техник хезмәт күрсәтү пунктларының федераль кагыйдәләр таләпләренә туры килүе (туры килмәве) турында федераль кагыйдәләр таләпләренә туры килүе турында кабул ителгән карар хакында вәкаләтле орган тиешле карар кабул ителгән көннән алып ике эш көне эчендә сайлауда катнашучыга хәбәр итә.»;

10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучылар тәкъдимне (заявканы) электрон төрдә дә, кәгазь чыганакта да бирергә хокуклы. Тәкъдимне (заявканы) электрон төрдә бирү «ГБО.РФ газ-мотор ягулыгы базарының бердәм платформасы» (алга таба – ГБО платформасы) сервисының рәсми сайты аша гамәлгә ашырыла. Сайлап алуда катнашучы ГБО платформасында катнашу өчен заявка бирә. Тәкъдимне (заявканы) электрон төрдә тапшырганда теркәлә торган документлар сайлап алуда катнашучы тарафыннан аларның сканерланган күчермәләре рәвешендә тапшырылырга тиеш. Техник сәбәпләр аркасында ГБО платформасы аша тәкъдим (гариза) бирү мөмкин булмаганда, сайлап алуда катнашучы документларның сканерланган, сайлап алуда катнашучының электрон имзасы белән таныкланган, законнарда билгеләнгән тәртиптә (электрон имза булганда) zip архивында булдырылган күчермәләрен gmt.ppto@mail.ru адресы буенча электрон почтага җибәрә.

Сайлап алуда катнашу өчен тәкъдим (заявка) электрон төрдә бирелгәндә сайлап алуда катнашучы вәкаләтле органга түбәндәге документлар белән тәкъдим (заявка) бирә:

әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтада бирелгән форма буенча субсидия бирү турында гариза;

әлеге Тәртипкә 3 нче кушымтада бирелгән форма буенча гарантия хаты;

әлеге Тәртипкә 4 нче кушымтада бирелгән форма буенча әлеге Тәртипнең таләпләре нигезендә үткәрелгән эшләр турында гарантия хаты;

транспорт чаралары хуҗасының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә шәхси мәгълүматларын бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалыгының күчермәсен теркәп, Россия Федерациясе гражданы – транспорт чаралары хуҗасы паспортының (Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яки Индивидуаль эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә) күчермәсе;

транспорт чараларын теркәү турындагы таныклыкның күчермәсе;

газ баллоны җиһазын сатуны һәм (яки) аны транспорт чараларына урнаштыруны күздә тота торган транспорт чараларын яңадан җиһазландыру турындагы шартнамәнең барлык өстәмә килешүләре белән (әлеге Тәртип белән расланган мондый шартнамәгә таләпләр нигезендә) күчермәсе;

башкарылган эшләр актының һәм транспорт чараларын яңадан җиһазландыру турындагы шартнамә буенча түләү турындагы документның күчермәсе. Шул ук вакытта физик зат белән төзелгән транспорт чараларын яңадан җиһазландыру турындагы шартнамәдә түләүләрне кичектереп түләү каралган булса, әлеге кичектереп түләүне раслый торган документ һәм (яисә) акчалата йөкләмәләр буенча таләпләр бирү турында килешү тапшырыла;

әлеге Тәртипкә 5 нче кушымтада бирелгән форма буенча транспорт чараларын яңадан җиһазландыру турында хисап;

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан транспорт чаралары конструкциясенә үзгәрешләр кертүгә бирелгән рөхсәт кәгазенең күчермәсе;

лизинг бирүченең транспорт чаралары конструкциясенә үзгәреш кертүгә ризалыгы (әгәр транспорт чаралары хуҗасы лизинг бирүче булса);

транспорт чараларын арендалау шартнамәсенең күчермәсе һәм транспорт чаралары хуҗасының транспорт чаралары конструкциясенә (әгәр аренда шартнамәсе төзелгән булса) үзгәреш кертүгә ризалыгы;

урнаштырылган газ баллоны паспортының һәм урнаштырылган газ баллоны җиһазына сертификатның күчермәсе;

двигатель паспортының күчермәсе яки двигательне сатып алу-сату шартнамәсенең күчермәсе (транспорт чаралары моторын алыштырган очракта);

кулланылган газ балоны җиһазына спецификациянең күчермәсе һәм транспорт чараларын яңадан җиһазландыру буенча башкарылган эшләрнең кыйммәтен һәм әлеге эшләргә бирелгән ташламаның исәп-хисабын күрсәтеп, транспорт чараларын яңадан җиһазландыру буенча башкарылган эшләр исемлеге;

урнаштырылган җиһазга сертификат номерын һәм баллон номерын күрсәтеп, двигательне газсыман ягулык белән тәэмин итү өчен транспорт чараларына җиһаз урнаштыру эшләрен башкаручы декларациясенең күчермәсе;

сайлап алуда катнашучы һәм транспорт чаралары хуҗасы арасында төзелгән ниятләр турындагы килешүнең күчермәсе (сайлап алуда катнашучы тарафыннан

транспорт чаралары хуҗасы һәм «Газпром газ-мотор ягулыгы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте белән яки табигый газ (метан) сатуны гамәлгә ашыручы башка оешма белән өчьяклы килешү төзелгән очракта);

сайлап алуда катнашучы тарафыннан, транспорт чараларының идентификация номерын, транспорт чаралары маркасын, транспорт чаралары хуҗасының фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы – булганда) яки атамасын, аның элемтәгә керү өчен телефон номерын һәм факттагы яшәү урынын яки урнашу урынын күрсәтеп, транспорт чаралары хуҗасына һәм транспорт чараларын яңадан җиһазландыру эшләрен башкару өчен фактта ташлама бирүне һәм аның күләмен документаль раслау (башкарылган эшләр акты, счет-фактура, чек һәм башкалар);

сайлап алуда катнашучы тарафыннан транспорт чараларын газ ягулыгына яңадан җиһазландыру эшләрен үткәрү турындагы Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хәбәрнамәсен раслый торган документның күчермәсе;

салым органының тәкъдим (заявка) биргән айга кадәрге айның 1е хәленә карата бирелгән салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмә булмауны раслый торган белешмә кәгазен;

сайлап алуда катнашучының Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләрне, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы каршында акчалата йөкләмәләр буенча үз вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычы булмау;

сайлап алуда катнашучы юридик зат үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашкан юридик затка башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмау, аңа карата банкротлык процессы билгеләнмәү, сайлап алуда катнашучы эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмау, ә сайлап алуда катнашучы индивидуаль эшмәкәр үз эшчәнлеген индивидуаль эшмәкәр буларак туктатмау;

сайлап алуда катнашучының офшор компаниясе, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмавын раслый торган, сайлап алуда катнашучы белешмәсе;

сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртиптә билгеләнгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмавы турында сайлап алуда катнашучының белешмә кәгазе;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелә торган тәкъдим (заявка), тиешле сайлап алуга бәйле сайлап алуда катнашучы турында башка мәгълүматны бастырып чыгаруга (урнаштыруга) язма ризалык;

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының бердәм реестрыннан өземтә (кирәк булганда).

Сайлап алуда катнашучы тарафыннан Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының бердәм реестрыннан өземтә (кирәк булганда) бирелмәсә, вәкаләтле орган әлеге белешмәне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән яки ведомствоара хезмәттәшлек тәртибендә ала.

Салым органының тәкъдим (заявка) биргән айга кадәрге айның 1е хәленә карата бирелгән салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмә булмауны раслый торган белешмә кәгазенең күчермәсе сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелмәгән очракта, вәкаләтле орган әлеге мәгълүматларны ведомствоара хезмәттәшлек тәртибендә ала.

Сайлап алуда катнашучы заявканы сайлап алу тәмамланганга кадәр теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы. Сайлап алуда катнашучы, кирәк булганда, заявкалар бирү өчен билгеләнгән срок эчендә заявканы кабат бирергә хокуклы, шул ук вакытта заявка, керү вакытын күрсәтеп, чират тәртибендә кергән көндә теркәүгә алына.»;

11 пунктта:

тугызынчы абзацка «, һәм (яисә) акчалата йөкләмәләр буенча таләп итү хокукларын бирү турында килешү» сүзләрен өстәргә;

егерме дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуда катнашучының офшор компаниясе, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмавын раслый торган, сайлап алуда катнашучы белешмәсе;»;

13 пунктта:

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«вәкаләтле орган сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән сайлап алу үткәрү срогы тәмамланган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә сайлап алу нәтиҗәләре турында (сайлап алуны үткәрү йә тәкъдимне (заявканы) кире кагу турында) реестр төзи һәм җиңүчеләр турында карар һәм субсидия бирү турында карар кабул итә;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Агымдагы финанс елында бюджет йөкләмәләре лимитлары җитмәүгә бәйле рәвештә субсидия бирүдән баш тартылган субсидия алучы чираттагы финанс елында кабат сайлап алуны узмыйча субсидия алырга хокуклы.»;

16 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Субсидия бирү өчен нигез булып вәкаләтле органның сайлап алуда җиңүчеләр һәм субсидия бирү турында карары тора.»;

өченче абзацта «субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләре» сүзләрен «субсидия бирү тәгәлләнә торган төгәл дата һәм аны бирү нәтиҗәсенең соңгы күрсәткече (йомгакларның төгәл микъдари тасвирнамәсе)» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге Тәртипкә 3 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

әлеге Тәртипкә 4 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

әлеге Тәртипкә 7 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Транспорт чараларына кысылган табигый газ салу объектларын төзүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләрдән тыш) һәм индивидуаль эшмәкәрләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 28 октябрь, 1008 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 6 октябрь, 1074 нче карары beläщн кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Транспорт чараларына кысылган табигый газ салу объектларын төзүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләрдән тыш) һәм индивидуаль эшмәкәрләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Субсидия алучыларны сайлап алу, сайлап алуда катнашучының сайлап алу критерийларына һәм тәкъдимнәр (гаризалар) керү чиратына туры килүеннән чыгып, сайлап алуда катнашучы өчен сайлап алуда катнашучылар тарафыннан җибәрелгән тәкъдимнәр (гаризалар) нигезендә вәкаләтле орган тарафыннан үткәрелә.

Сайлап алуны үткәрү турында белдерү, сайлап алу үткәрелү көненә кадәрге өч календарь көнннән дә соңга калмыйча, Россия Федерациясе бюджет системасының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге бердәм порталында һәм вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында https://mpt.tatarstan.ru/ урнаштырыла.

Сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

сайлап алуны үткәрү сроклары;

тәкъдимнәр (заявкалар) бирә башлау яки кабул итүне тәмамлау даталарын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 календарь көннән иртәрәк була алмый);

бу Тәртипнең 17 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәләре;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган сайтның домен исеме, һәм (яки) челтәр адресы, һәм (яки) битләр күрсәткечләре;

әлеге Тәртипнең 5 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләр һәм сайлап алуда катнашучылар тарафыннан күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеге;

әлеге Тәртипнең 6 пункты нигезендә сайлап алу критерийлары;

әлеге Тәртипнең 7 һәм 8 пунктлары нигезендә тәкъдимнәр (гаризалар) бирү тәртибе һәм тәкъдимнәрнең (гаризаларның) формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләр;

тәкъдимнәрне (заявкаларны) кире алу тәртибе, тәкъдимнәрне (заявкаларны) кире кайтару (шул исәптән тәкъдимнәрне (заявкаларны) кире кайтару өчен нигезләр билгеләнә торган) тәртибе, тәкъдимнәргә (заявкаларга) үзгәрешләр кертү тәртибе;

бу Тәртипнең 14 пункты нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләре;

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрү турында белдерү нигезләмәләренә аңлатма бирү тәртибе, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасы;

сайлап алуда җиңүче тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә имза кую вакыты;

сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) Субсидия бирү турындагы килешүне төзүдән баш тарткан дип тану шартлары;

сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңга калмыйча, Россия Федерациясе бюджет системасының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге бердәм порталында һәм вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алу нәтиҗәләрен урнаштыру датасы.»;

5 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуда катнашучылар чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмау. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

7 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Тәкъдимне (заявканы) электрон төрдә бирү «ГБО.РФ газ-мотор ягулыгы базарының бердәм платформасы» (алга таба – ГБО платформасы) сервисының рәсми сайты аша гамәлгә ашырыла. Тәкъдимне (заявканы) электрон төрдә тапшырганда теркәлә торган документлар сайлап алуда катнашучы тарафыннан аларның сканерланган күчермәләре рәвешендә тапшырылырга тиеш. Техник сәбәпләр аркасында ГБО платформасы аша тәкъдим (гариза) бирү мөмкин булмаганда, сайлап алуда катнашучы документларның сканерланган, сайлап алуда катнашучының электрон имзасы белән таныкланган, законнарда билгеләнгән тәртиптә (электрон имза булганда) zip архивында булдырылган күчермәләрен gmt.ppto@mail.ru адресы буенча электрон почтага җибәрә.»;

13 пунктның икенче абзацында «субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткечләре» сүзләрен «субсидия бирү төгәлләнә торган төгәл дата һәм аны бирү нәтиҗәсенең соңгы күрсәткече (йомгакларның төгәл микъдари тасвирнамәсе)» сүзләренә алмаштырырга»;

21 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21. Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан

Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталындагы «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин